ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск шәһ. **КАРАР**

**28.01.2019 г.** **№ 199**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылык һәм экстремизм профилактикасын 2018-2020 елларда муниципаль программага кертү турында

2018 елның 28 декабрендә Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин раслаган 2019-2023 елларда Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәш Комплексլы планын башкару өчен һәм Зеленодольск муниципаль районында теророрчылык идеологиясенә каршы көрәшү системасын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР ИТӘ:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 мартындагы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2018-2020 елларда террорчылык һәм экстремизм профилактикасы муниципаль программасын раслау турында» 696нчы карары белән расланган 2018-2020 елларда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылык һәм экстремизм профилактикасы муниципаль программасына (алда – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) Программаның 11нче бүлегендә күрсәтелгән «Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 апрелендә раслаган 2013-2018 елларда Россия Федерациясендә террорчылык иделогиясенә каршы көрәш Комплекслы планы чаралары»н башкарылган дип исәпләргә һәм контрольдән алырга;

2) Программаның «Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 апрелендә раслаган 2013-2018 елларда Россия Федерациясендә террорчылык иделогиясенә каршы көрәш Комплекслы планы чаралары» 11нче бүлеген кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә чыгарырга;

2. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек җитәкчесе Д.С. Анисимовка бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыруныа тәкъдим итәргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.А. Сапожников

Кушымта

| №№ пп | Чара исеме | Башкаручылар | Финанслау күләме (мең сум) | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| **11.2018 елның 28 декабрендә Россия Федерациясе Президенты раслаган 2019 – 2023 елларда Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору Комплекслы планын гамәлгә ашыру чаралары** | | | | | | |
| 51. | Затларның террорчылык эшчәнлеге тәэсиренә бирелүдән һәм шулай ук аның тәэсире астына эләгүдән кисәтү максатыннан чаралар уздырырга: | | | | | |
| 51.1 | - террорчылык характерында җинаятьләр кылган өчен җәза узган затларны социализацияләүгә юнәлтелгән Россия Федерациясе законнарында каралган социаль-икътисади чараларны гамәлгә ашыру буенча; | ЯҮМРда АТК,<br>ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br>ЯҮМР БК җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр),<br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге | * | | | |
| 51.2 | -җинаять җәзасын үтәтү системасында җәза үтәүче затлар белән, дини һәм җәмәгать оешмалары вәкилләрен, | ТР буенча | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | психологларны җәлеп итеп, террорчылыкның җинаятьчел асылын аңлату буенча информацион-пропаганда чаралары; | УФСИНның ИК-5,<br><br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге | | | | |
| 51.3 | -ирeгeн мәхрүм итүгә бәйле булмаган террорчылык характерындагы җинаятьләр кылган өчен җәза узган затларга, дини һәм җәмәгать оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп, индивидуаль әңгәмә формасында аларның җәмгыять, дәүләт каршында әхлакый һәм хокукый җаваплылыгын, террорчылык эшчәнлегенең социаль һәм хокукый нәтиҗәләре турында аңлатырга ; | ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br><br>ЯҮМР БК җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр),<br><br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллегеи,<br><br>ОМС башлыклары | * | | | |
| 51.4 | - террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган (гамәлдә булган, хөкем ителгән, нейтральләштерелгән), шул исәптән югары террорчылык активлыгы булган илләрдән кайткан затлар гаиләләре әгъзаларына террорчылык эшчәнлегендә катнашкан һәм ярдәм иткән өчен җаваплылык билгеләгән закон нормаларын әңгәмә формасында аңлатырга, шулай ук күрсәтелгән затларга дини һәм җәмәгать вәкилләре катнашында психологик һәм хокукый ярдәм күрсәтергә; | ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br><br>ЯҮМРның БК мәгариф идарәсе,<br><br>ЯҮМРның БК ның яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәсе,<br><br>Татарстан халыклары Ассамблеясе | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | вәкиллеге | | | | |
| 51.5 | -Россия Федерациясе территориясенә вакытлыча яшәү һәм хезмәт эшчәнлеге алып бару өчен килгән затларга террорчылык эшчәнлегендә катнашкан һәм ярдәм иткән, социаль, раса, милли һәм дини ызгыш чыгарган, Россия конституциясе нигезләрен көчләп үзгәртүгә юнәлтелгән максатлар һәм гамәлләр өчен, эш бирүчеләрне, дини һәм җәмәгать оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп, Россия Федерациясе законнары нормаларын аңлату. | ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br>ОМС башлыклары | * | | | |
| 51.6 | - Россия Федерациясе территориясенә югары террорчылык активлыгы булган илләрдән югары уку йортларына һәм урта һөнәри белем чараларына укырга килгән затларга террорчылык эшчәнлегендә катнашкан һәм ярдәм иткән, социаль, раса, милли һәм дини ызгыш чыгарган, Россия конституциясе нигезләрен көчләп үзгәртүгә юнәлтелгән максатлар һәм гамәлләр өчен, (дини һәм җәмәгать оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп), Россия Федерациясе законнары нормаларын индивидуаль яисә төркемләп әңгәмә формасында аңлату; | ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br>ЯҮМР БКның яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәсе,<br>ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе,<br>ОМС башлыклары, | * | | | |
| 51.7 | -чит илдә дини белем алып, Россия Федерациясе территориясендә дини эшчәнлек белән шөгыльләнергә теләүче затларга террорчылык эшчәнлегендә катнашкан һәм ярдәм иткән, яшәгән регионда традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм заман дини ситуациясенә карата җаваплылык билгеләгән Россия Федерациясе законнары нормаларын өйрәтү буенча эшне оештыру; | ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br>ТР буенча РФ ОУФСБ,<br>ОМС башлыклары,<br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге | * | | | |
| 51.8 | - яшьләр белән, шул исәптән профилактик исәптә торган һәм (яисә) Россия Федерациясенең эчке эшләр органнарында | ЗР буенча | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | административ күзәтчелек астында булган затларга җәмәгать иминлеге өлкәсендә хокук бозуларга катнашы булу сәбәпле дини, җәмәгать һәм спорт оешмалары вәкилләрен, психологларны җәлеп итеп, индивидуаль (төркем) әңгәмә формасында күрсәтелгән затларда террорчылык идеологиясенә каршылык күрсәтә һәм традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрне сеңдерә белүне а;лату. | РоссияОМВДсы,<br><br>ЯҮМР БКның яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәсе,<br><br>ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе,<br><br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге | | | | |
| 52. | Халыкта, иң беренче чиратта яшьләрдә террорчылык идеологиясен күрә алмауга юнәлтелгән террорчылыкка каршы аң, актив гражданлык карашы тәрбияләү максатыннан террорчылыкка каршы көрәштә Бердәмлек көненә (3 сентябрь) багышланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары уздырырга. Бу чараларны уздырганда күренекле федераль һәм региональ сәясәт эшлеклеләрен, абруйлы җәмәгать һәм дин оешмалары, фән, мәдәният һәм спорт вәкилләрен җәлеп итеп, халыкның бөтен төрле категориясенең катнашуын тәэмин итәргә. | ЯҮМР БКның яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәсе,<br><br>ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе,<br><br>ЯҮМР БКның<br><br>Мәдәният идарәсе | * | | | |
| 53. | Яшьләрдә террорчылык идеологиясе тәэсиренә бирешүчәнлеген киметү максатыннан чыгып: | | | | | |
| 53.1 | - мәгариф оешмалары базасында (шул исәптән дин һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашында) балаларда һәм яшьләрдә террорчылык идеологиясенә каршы тора белүне тәрбияләүгә һәм аларга традицион Россия рухи-әхлакый байлыкны сеңдерүгә юнәлтелгән тәрбияви һәм мәдәни-агарту чаралары уздырырга; | ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе,<br><br>ЯҮМР БКның | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Мәдәният идарәсе | | | | |
| 53.2 | - яшьләр, шул исәптән хәрби-патриотик яшьләр һәм балалар берләшмәләре мәнфәгатьләрен күрсәткән җәмәгать оешмалары һәм хәрәкәтләре эшчәнлегенә балаларда һәм яшьләрдә террорчылык идеологиясенә каршы тора белүне һәм традицион Россия рухи-әхлакый байлыкны сеңдерүне тәрбияләү буенча информацион һәм методик материалларны кертергә. Аларның эшчәнлегенә ярдәм итүне тәэмин итәргә; | ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе,<br><br>У ЯҮМР БКның яшьләр эшләре һәм спорт буенча идарәсе | • | | | |
| 53.3 | -мәгариф оешмаларының төп белем бирү программасына «Тормыш иминлеге нигезләре» фәне буенча укучыларда информацион иминлек мәсьәләләренә, шул исәптән балаларны «Интернет» челтәреннән файдаланганда террорчылык идеологиясен пропагандалаудан саклау мәсьәләләренә багышланган бүлекләрне кертүне оештырырга . | ЯҮМР БКның мәгариф идарәсе | * | | | |
| 54. | Террорчылык идеологиясен таратуда дини факторларны кулланыны юкка чыгару максатыннан дин әһелләре арасында профилактик эш формаларын һәм ысулларын камилләштерү мәсьәләләре буенча дини оешмалар (төркемнәр) җитәкчеләре белән даими очрашулар уздырырга. | ЯҮМР БК җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр),<br><br>Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге,<br><br>ОМС башлыклары | * | | | |
| 55. | Террорчылык иделогиясенә каршы көрәшкә юнәлтелгән информацион-пропаганданы камилләштерү чаралары: | | | | | |
| 55.1 | - террорчылык идеологиясенә каршы көрәш өлкәсендә, шул исәптән террорчылык эшчәнлегеннән һәм шулай ук аларның туганнарыннан баш тарткан затлар мөрәҗәгатьләренә | ЯҮМРда АТК, | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | (чакырулар) нигезләнгән информацион материалларны (басма, аудиовизуаль һәм электрон) җәмәгать фикере лидерларын җәлеп итеп, СМИда һәм «Интернет» челтәрендә булдыру һәм таратуны оештыру; | Районның СМИ | | | | |
| 55.2 | - террорчылык профилактикасы өлкәсендә информацион материалларны (басма, аудиовизуаль һәм электрон) халыкка җиткерү өчен халык күп була торган урыннарда тышкы реклама чараларын һәм мәгълүмат системасы җиһазларын куллануны тәэмин итәргә; | ЯҮМРда АТК,<br><br>ЯҮМР БК җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр), | * | | | |
| 56. | Мәгълүмат тирәлеген террорчылык идеологиясе таралудан саклау максатыннан «Интернет» челтәрендә террорчылык материалларын юкка чыгару буенча чаралар үткәрергә, шулай ук күрсәтелгән материаллар булган интернет – ресурсларга керүне судка кадәр тыярга. | «Кибердружина»,<br><br>ЗР буенча Россия ОМВДсы,<br><br>ТР буенча РФ ОУФСБсы,<br><br>прокуратура | * | | | |
| 57. | Террорчылык идеологиясенә каршы көрәш буенча чараларны гамәлгә ашыруда үз вәкаләтләре кысасында катнашкан муниципаль хезмәткәрләрне, шулай ук башка хезмәткәрләрне квалификация күтәрү курсларына җибәрүне тәэмин итәргә. | ЯҮМРда АТК,<br><br>ОМСның кадрлар хезмәте | * | | | |

* Искәрмә: Финанслау күләме планга кертелгән предприятиеләр һәм учреждениеләрнең агымдагы финанслары исәбенә алып барыла.